КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 23 май г.Казань № 732

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алга китеп һөнәри әзерләү үзәген төзү һәм аның эшләве өлешендә устав эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 11 февраль, 73 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Алга китеп һөнәри әзерләү үзәген төзү һәм аның эшләве өлешендә устав эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2025 ел, 11 февраль, 73 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «төзү өлешендә устав эшчәнлеген тәэмин итү һәм» сүзләрен «өлешендә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру чыгымнарын тәэмин итү (каплау)» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «төзү өлешендә устав эшчәнлеген тәэмин итү һәм» сүзләрен «өлешендә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру чыгымнарын тәэмин итү (каплау)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Алгарышлы һөнәри әзерләү үзәген төзү һәм аның эшчәнлеге өлешендә устав эшчәнлеген финанс белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү тәртибендә:

исемендә «төзү өлешендә устав эшчәнлеген тәэмин итү һәм» сүзләрен «өлешендә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру чыгымнарын тәэмин итү (каплау)» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «шулай ук физик затлар - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга, «төзү өлешендә устав эшчәнлеген тәэмин итү һәм» сүзләрен «өлешендә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыру чыгымнарын тәэмин итү (каплау)» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта «чыгымнарын түләү, оештыру һәм белән бәйле барлыкка килүче» сүзләрен «чыгымнарын түләү (компенсацияләү), үз эшчәнлеген үтәү, белән бәйле барлыкка килүче» сүзләре белән алыштырырга;

3 пунктта «тәэмин итү, җәмәгать оешмасының үтәгәнлеге өчен, барлыкка килгән» сүзләрен «тәэмин итү, җәмәгать оешмасының үтәгәнлеге өчен, барлыкка килгән» сүзләре белән алыштырырга;

5 пунктта «, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

7 пунктның бишенче абзацында «төзүгә юнәлдерелгән һәм» сүзләрен «юнәлдерелгән» сүзенә алмаштырырга;

11 пунктта «финанс белән тәэмин итү» сүзләреннән соң «(каплау)» сүзен өстәргә;

12 пунктта:

беренче абзацка «, һәм (яки) аларны каплау өчен субсидия бирелә торган чгымнар» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацка «төзүне тәэмин итә һәм» сүзләрен «тәэмин итә» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «төзү белән бәйле һәм» сүзләрен «белән бәйле» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «төзүне тәэмин итә һәм» сүзләрен «тәэмин итә» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «төзү белән бәйле һәм» сүзләрен «белән бәйле» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яшәгән өчен түләү буенча - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Табыш чараларын классификацияләү турындагы нигезләмәне раслау турында» 2024 елның 27 декабрендәге 1951 номерлы карары нигезендә беренче категориянең (стандартның) бер урынлы номерының базар бәяләре турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт булган чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта мәгълүмат анализында, «Интернет» челтәрендәге башкаручыларның рәсми сайтларын да кертеп;»;

13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Алдан һөнәри әзерлек үзәге эшчәнлеге өлешендә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия күләме (Сфо) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_{фо} = Р_1 + Р_2 + Р_3 + Р_4,$$

монда:

$Р_1$, $Р_2$, $Р_3$, $Р_4$ – әлеге Тәртипнең 12 пунктындагы икенче – бишенче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча смета чыгымнары.

Алдан һөнәри әзерлек үзәге эшчәнлеге өлешендә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнарга субсидия күләме (Свз) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С_{вз} = З_1 + З_2 + З_3 + З_4,$$

монда:

$З_1$, $З_2$, $З_3$, $З_4$ – әлеге Тәртипнең 12 пунктының икенче - бишенче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча гамәлдә башкарылган чыгымнар.»;

25 пунктта:

бишенче абзацта «төзүгә юнәлдерелгән һәм» сүзләрен «юнәлдерелгән» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Алдан һөнәри әзерлек үзәге эшчәнлеге өлешендә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия алу өчен коммерциягә карамаган оешма шулай ук Алдан һөнәри әзерлек үзәге эшчәнлеге өлешендә устав эшчәнлеге белән бәйле килешүләр төзү планлаштырыла торган, алар буенча субсидияләр акчалары исәбеннән түләнә торган проектларны тәкъдим итә.

Алдан һөнәри әзерлек үзәге эшчәнлеге өлешендә устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә субсидия алу өчен коммерциягә карамаган оешма шулай ук тапшыра:

Алдан һөнәри әзерлек үзәге эшчәнлеге өлешендә устав эшчәнлеге белән бәйле төзелгән, алар буенча субсидияләр акчалары исәбеннән түләнә торган килешүләр;

төзелгән шартнамәләрне башкару турында беренчел документация;

Россия Банкының «Кулдагы исәп-хисап кагыйдәләре турында» 2019 елның 9 декабрендәге 5348-У номерлы күрсәтмәсе нигезендә рәсмиләштерелгән түләү документлары (счетлар, счет-фактуралар, товар-транспорт накладнойлары, түләү йөкләмәләре, керү һәм чыгу ордерлары).»;

46 пунктка «(чыгымнарны финанс ягыннан тәэмин итүгә субсидия бирелгән очракта)» сүзләрен өстәргә»;

49 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

55 пунктның беренче абзацында татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

56 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин